# Ромашка сулышы

**Ата – аналар өчен махсус басма (март, 2025)**

## ЖИТӘКЧЕ СҮЗЕ:

Жылы кояш нурларына һәм тамчылар чыңына төренеп язның беренче ае – март та килеп житте. Барыбызга да билгеле – әлеге айның иң зур бәйрәме – 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне.

Кадерле әниләр, ягымлы әбиләр һәм дәү әниләр, нәни кызларыбыз! Сезне чын күңелдән язның тәүге бәйрәме белән тәбриклибез! Бу матур бәйрәм көнендә безнең ихлас котлауларыбызны кабул итегез. Язгы гөрләвекләр сезнең тормышыгызга жылылык, саулык-сәламәтлек, эшегездә уңышлар, күңел тынычлыгы, күтәренке кәеф, бәхет алып килсен! Сезнен тормышыгыз яхшылык һәм яктылык, мәхәббәт, якыннарыгызның күңел жылысы һәм игътибары белән тулып, йөзләрегез елмаюдан ябтырып, нурлар чәчеп торса иде!

## Март аеның истәлекле көннәре:

– 1 март - Россиядә песиләр көне
– 2 март - Халыкклара шырпы көне
– 2 март - Халыкклара балалар телевидениесе көне
– 8 март - Халыкара хатын-кызлар Көне
– 12 март - Чәчәкләр утырту көне
– 14 март - Халыкара елгалар көне
– 16 март - Төсле карандашлар көне
– 20 март - Дөньякүләм чыпчыклар көне
– 21 март - Язгы көн һәм төн тигезләшкән көн
– 21 март - Халыкара урманнар көне
– 27 март - Бөтендөнья театр көне
– 29 март - Дөньякүләм фортепиано көне

## УЗГАН АЙ НӘТИЖӘЛӘРЕ

**7нче февраль** көнне «Россия чаңгы юллары – 2025» ярышында балаларыбыз бик теләп катнаштылар һәм күркәм нәтиҗәләргә ирештеләр. Мәктәпкәчә яшьтәге малайлар арсында Рахматуллин Гадел 1нче урын, Нурлыев Алмаз 4нче урын, кызлар арасында Бакирова Айсылу 1нче урын, Хазиева Сафия 4нче урын яуладылар. Гаиләләр эстафетасында призлы өчлекнең өченче баскычында Бакировлар, икенче баскычында Хазиевлар гаиләләре урын алды. Аз гына аерма белән Рахматуллиннар гаиләсе 4нче урынга ия булды.

**15нче февраль** герой шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне уңаеннан уздырылган III республика «Кызыл ромашка» бәйгесе «Нәфис сүз» номинациясендә 2кечкенәләр төркеменнән Аглямова Эмилия (җитәкчесе Г.Р.Галимарданова) III дәрәҗә, зурлар төркеменнән Маннанов Алмаз (җитәкчеләре Г.Р.Гайнуллина һәм З.Р.Гыйль-фанова) I дәрәҗә җиңү яуладылар.

**18нче февраль** көнне мәркәзебез Казанда «Җәлил укулары» әдәби бәйгесенә нәтиҗә ясалып зур концерт-тамаша үтте. Мәктәпкә әзерлек төркеменнән Гаянов Раяз мактаулы 3нче урынга лаек булып Г.Камал театры сәхнәсендә чыгыш ясады.

**19нчы февраль** көнне бакчабыз педагоглары «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда сәламәт яшәү рәвеше нигезләрен формалаштыру» проекты белән Мөслим, Сарман районнарының мәктәпкәчә тәрбия методистлары алдында тәҗрибә уртаклашты.

**20нче февраль** көнне Ә.Авзалова исемендәге район мәдәният йортында балалар бакчалары арасында «Йолдызлык» XXV эстрада сәнгатенең ачык республика телевизион яшьләр фестивале муниципаль этабы үтте. Әлеге бәйгедә бакчабыздан 32 бала катнашты. Нәтиҗәләр түбәндәгечә:

**«Конферанс» номинациясе:**
Закирова Мәликә, Низамова Әминә – II дәрәҗә,
Маннанова Диләрә – II дәрәҗә.

**«Нәфис сүз» номинациясе**:
Маннанов Алмаз – I дәрәҗә,
Миннеханова Лиана – II дәрәҗә,
Маликов Рамазан – III дәрәҗә,
Нурлыев Алмаз – III дәрәҗә.

**«Вокал-соло» номинациясе:**
Низамова Әминә – I дәрәҗә,
Маннанова Диләрә – I дәрәҗә,
Фархтдинов Самир – II дәрәҗә,
Гаянов Раяз – II дәрәҗә,
Местакова Зәлия – III дәрәҗә

**«Вокал-ансамбль» номинациясе:**

Мәктәпкә әзерлек төркеме кызлары – I дәрәҗә,

Мәктәпкә әзерлек төркеме малайлары - III дәрәҗә.

**«Хореография-эстрада биюләре» номинациясе**: Дингезче биюе – III дәрәҗә.

**«Хореография-халык биюләре» номинациясе:** Дуслык биюе – I дәрәҗә.

**21нче февраль** көнне Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты һәм. Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан оештырылган Илһам Шакиров җырларына төшерелгән республикакүләм анимацион фильмнар бәйгесендә зурлар төркеменнән Вагыйзов Тауфик остазлары Зәйнәп Робертовна һәм Алисә Фәндәсовна белән берлектә төшергән «Ай, былбылым» фильмы I дәрәҗә дипломга лаек булды.

**23нче февраль** – Ватанны саклаучылар көне уңаеннан төркемнәрдә бәйрәм иртәләре узды.

**27нче февраль** көнне «Актаныш гомуми үсеш бирүче 4 балалар бакчасы» тарафыннан уздырылган «Минем гаиләм, экология һәм мин» район бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. «Минем гаилә экологиясе» номинациясендә Насрыевлар гаиләсе (җитәкчесе – А.М.Хабибуллина) II дәрәҗә, «Гаиләм экоостаханәсе» номинациясендә Яхиннар гаиләсе (җитәкчесе – Л.Г.Лотфуллина) җиңүче, «Волонтерлык инициативасы» номинациясендә Хисматуллиннар гаиләсе (җитәкчесе – З.Р. Гыйльфанова) II дәрәҗә дипломнарга ия булдылар.










**Шәфкать туташы киңәш бирә**

## БАЛАНЫ ЯЗГЫ АВЫРУЛАРДАН НИЧЕК САКЛАРГА?

Яз – табигатьнең яңару һәм уяну вакыты. Ләкин шуны да онытмаска кирәк: җылы кояш нурлары һәм язгы чәчәкләр белән бергә салкын тию авырулары куркынычы кабаттан яңарырга мөмкин. Кышкы озакка сузылган суыклар һәм кояш яктылыгы кимү – балаларның иммунитеты кимүгә һәм организмның хәлсезләнүенә китерә. Шул сәбәпле көннәр җылы торуга карамастан яз айларында салкын тиеп авыру очраклары еш күзәтелә.

Кыш айларында бала авырмаса да аның организмы вируслар белән "көрәшү" нәтиҗәсендә хәлсезләнә, иммун системасы ресурслары ярлылана, кирәкле витаминнар һәм минераллар запасы бетә. Шуңа бәйле рәвештә хәлсез, зәгыйфь организм төрле вируслы инфекцияләрне мөстәкыйль рәвештә җиңә алмый һәм авыруның көчәюенә китерергә мөмкин. Антибиотиклар кабул итү иммунитетның тагын да көчсезләндерә.

Бу вакытта балалар авырмасын өчен нишләргә кирәк соң?

Иң беренче киңәш – йокы режимын төгәл үтәү. Җитәрлек йокы – сәламәтлекнең төп нигезе. Яңа көнгә көч, энергия туплау өчен мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәүлегенә 9-10 сәгать йокы таләп ителә. Әгәр баланың йокы вакыты моннан азрак булса, аны иртәрәк йокларга яткырырга кирәк. Соңлап яту һәм йокыдан иртә тору баланың сәламәтлегендә һәм кәефендә тискәре йогынты тапмый калмый.

Икенче киңәш итеп дөрес туклануны ассызыклап үтәсе килә. Кибет киштәләрендә төсле, матур кәгазьләргә төрелгән баллы ризыклар янынннан балалар тыныч кына үтеп китә алмыйлар. Күп очракта әти-әниләр дә баланың кәефен төшермәс өчен аларның теләкләрен үтәргә тырышалар. Ләкин баланың туклану рационын яшелчәләр, җиләк-җимешләр белән баетырга кирәк. Чиста су, яшелчә соклары эчүне арттырырга кирәк.



Өченче киңәш – һава торышына карап дөрес киенү. Бик җиңел киенгән бала тиз туңа, артык җылы киенгәне тиз тирли – шуның өчен юка киемнәрне катлы-катлы кигәнче, калын итеп бер кием кию отышлы була. Аяк киеменең дә су үткәрми торганнарына өстенлек бирергә кирәк. Баланың шкафында алмаш майка, футболка, носки булуын тәэмин итәргә тырышыгыз.

# *Сигезенче март – Әни бәйрәме,*
# *Бүләк итәрмен чәчәк бәйләме…*

Бакчабыз нәниләре 8 Март – Халыкара Хатын-кызлар көнен сагынып көтеп алдылар. Үзләренең әниләренә һәм әбиләренә бәйрәм белән котлап матур открыткалар ясадылар, тәрбияче апалары ярдәме белән җылы теләкләр һәм котлаулар яздылар, шигырьләр, җырлар өйрәнделәр.

Иң кечкенәләребезнең әниләргә котлавы:



Уртанчылар төркеме балалары әниләрне котлый:




Беренче кечкенәләр төркеме нәниләре бүләге:



Зурлар төркеме балалары әниләргә матур гөл үстерделәр:



Икенче кечкенәләр төркеме малайлары бәйрәм белән котлый:




Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларыннан бәйрәм открыткалары:



# Котлы булсын, Туган көнегез!

**Хөрмәтле тәрбиячеләребез Рәзинә Рафил кызы һәм Эльвира Валерий кызы!**

Сезне чын күңелдән гомер бәйрәмегез белән тәбрик итәбез!

Сезгә иң изге, якты, матур теләкләребезне юллыйбыз: көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел, бәхетле һәм сәламәт булыгыз! Уй-теләкләрегез матур, туар таңнарыгыз тыныч, саулыгыгыз ныклы, гомерегез бәхетле булсын! Тормышыбызга ямь өстәп, авырмый, кайгы-хәсрәт күрми, озын гомер итүегезне, балаларыгыз, якыннарыгызның игелеген күреп ак бәхетләр белән мул тормышта яшәвегезне телибез!

Март аенда дөньяга аваз салган балаларыбыз – Бәдретдинова Мәрьям, Рахматуллин Гадел, Сагитова Камилла, Мухаметдинова Ралина, Закиров Ильяс, Рашитова Милена, Саетова Камилә, Насриев Рузил, Анварова София, Шарафуллин Денисны чын күңелдән туган көннәре белән тәбриклибез! Сау-сәламәт, бәхетле, тәүфыйклы балалар булып үсүегезне, Әти-Әниле матур, бәхетле балачак телибез!

Котлы булсын туган көннәрегез
Көлеп торсын һәрчак күзләрегез.
Матур булсын тормыш юлларыгыз,
Сез бит безнең матур гөлләребез.

## БЕРГӘЛӘП ЗУР ҖИҢҮЛӘРГӘ...

(мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен бәйге-конкурслар)

Бөтендөнья татар конгрессы һәм Азнакай муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында **«Татар поэзиясе классиклары»** шигырь сөйләүчеләр бәйгесе уздыра. Бәйгенең шартлары – нигезләмәдә тәкъдим ителгән шигырьләрне яттан сөйләп mp4, wmv, avi форматында видео ясарга һәм 2025 елның 15 маена кадәр 2025konkurs@mail.ru электрон адресына җибәрергә. Нигезләмә белән тулырак түбәндәге сылтама аша таныша аласысыз.

Казан шәһәре «Инновацион укыту һәм компетенцияләрне үстерү регионара үзәге» **«Минем бәхетле гаиләм»** рәсем конкурсы оештыра. Рәсемнәр гаилә, гаилә кыйммәтләре һәм традицияләре темасына багышланырга, ата-аналар һәм педагоглар ярдәменнән башка башкарылырга тиеш. Рәсемнәрне 14 апрельгә кадәр inneducation@mail.ru адресына җибәрергә кирәк. Нигезләмә белән тулырак түбәндәге сылтама аша таныша аласысыз.

Түбән Кама шәһәре Мәгариф идарәсе, Яр Чаллы шәһәре «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУ территориаль бүлеге белән берлектә **«Хәрәкәт инспекторларының яшь ярдәмчеләре»** («Звезда ЮПИД») бәйгесе оештыра. Балаларның юл хәрәкәте иминлеге темасына кызыксынуын арттырасыгыз килсә – әлеге бәйге шәп мөмкинлек. Нигезләмә буенча төшерелгән видеоларны 2025 елның 16 апрелена кадәр sadik381954@mail.ru электрон адресына юлларга кирәк. Бәйге турында тулырак сылтама аша кереп таныша аласыз.

Апрель аенда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көнен билгеләп үтәбез. Шул уңайдан балалар өчен әдәби бәйгеләр шактый оештырыла. 5-7 яшьлек балаларыбызны шундый чараларның берсендә катнашырга чакырабыз. Әти-әни белән **берлектә «Мин – Тукай варисы»** темасына 3 минуттан артмаган видеоязманы 14 апрельгә кадәр tykajvarislar@mail.ru электрон адресына җибәрергә кирәк. Бәйге турында тулырак сылтама аша кереп таныша аласыз.

**Газетаның электрон басмасы:**

Газетаны гамәлгә куючы – балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе **Хисматуллина Лилия Фәрит кызы**

**Балалар бакчасы адресы:** Актаныш авылы, Тынычлык проспекты, 35 А
mdou2-aktansh@mail.ru